КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 март г.Казань № 111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 май, 424 нче карары белән расланган Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 7 май, 424 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 31 май, 663 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары нигезендә эшләнде.»;

2.3 пунктта:

үндүртенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

җиденче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

3.8 пунктның унөченче абзацына «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Бу карар (әлеге карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы дүртенче – җиденче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин